**Тема:** Кешеләргә тапшырылган байлык (Шаһитова Васпиҗамал Шаһит кызына багышлана).

**Место выполнения работы:** МБОУ «Пелевская» СОШ, Лаишевский район, с. Пелево, Республика Татарстан.

**ФИ автора работы:** Зайнуллин Инсаф.


**ФИО руководителя:** Зайнуллина Зелфия Аделзяновна.

**Год:** 2016

**Иҗади эшемнең темасы:** Кешеләргә тапшырылган байлык (Шаһитова Васпиҗамал Шаһит кызына багышлана).




Џаһитова Васпиҗамал Шаһит кызы 1929 нчы елның 1 нче августында Татарстанның Лаеш районы Пәрәү авылында дөньяга килә. Балачагы ачлык елларына туры килә. 14 яшендә сыер савучы булып эшкә урнаша.





1958 елда “Иң яхшы сыер савучы” дигән мактаулы исем бирелә һәм Мәскәүдә Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашып, ВСХВ медалена лаек була.








Күргәзмәдә катнашуның истәлеге


булып,  таныклыгы да саклана.



КПССның Өлкә Комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының карары белән 1958 елда, социалистик ярышта югары күрсәткечләргә ирешүе өчен, “Татарстан АССРның иң яхшы сыер савучысы” дигән исем бирелә.



1969 нчы елның 25 ноябрендә РСФСР авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан бирелгән “Терлекчелек мастеры” дигән мактаулы исемгә лаек була. Шул исемне дәлилләп, таныклык тапшырыла.





1971 нче елның 11 февралендә “Районда 1970 нче елның иң яхшы сыер савучысы” дигән исемне яулый һәм таныклык белән беркетелә.

Шаһитова Васпиҗамал Шаһит кызы 1975 елда Социалистик ярышта  җиңеп чыга һәм “Социалистик ярыш ударнигы” дигән медальгә лаек була.






Тырыш хезмәте өчен, 1970 елда “В.И. Ленинның 100 еллык юбилее” медале белән бүләкләнә.




“9 нчы бишьеллыкның ударнигы”исеменә лаек була, нагрудной знак белән бүләкләнеп кителә.



Хезмәттә тиңдәшсез батырлыгы өчен грамоталар белән бүләкләнә.



Бөек Ватан сугышы чорында үзенең хезмәте белән Бөек Җиңүгә өлеш керткәне өчен, медальләр һәм төрле бүләкләр тапшырыла.
















Сугыш ветераны дигән таныклык тапшырыла.






1974 елда КПСС составына әгъза булып кабул ителүе зур вакыйга була.

Авыл халкының ышанычын, хөрмәтен яулаган Шаһитова Васпиҗамал Шаһит кызы Пәрәү авыл Советына депутат булып сайлана.






“Хезмәт ветераны” дигән

мактаулы исемгә лаек була.

41 ел буе гомерен фидакарь хезмәттә үткәргән Васпиҗамал әби, 55 яшен тутыргач, пенсиягә чыга. Лаеклы ялда кызы һәм кияве, оныклары белән тыныч картлыгын үткәрә.

2014 нче елның 14 нче августында, 85 яшендә,  якты дөнья белән саубуллашып бакыйлыкка күчә.





***Җирдә кеше торса торсын,
Эзе калсын тирән булып,
Үзе үлсә ,эше калсын,
Мең яшәрлек имән булып!***

**М.Җәлил**

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!